СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

09.11.2015 с.Соболевское 3-20

Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Уставының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

«2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль законның 3 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 2015елның 30 сентябрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Соболевский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Уставының 2016 нчы елның 1 нче гыйнварына кадәр Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге бюджеты проектын төзү һәм раслауга карата аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Советына күрсәтелгән проект белән бер үк вакытта план чорына материаллар тапшырунытуктатып торырга (Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразыннан, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова